КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 октябрь г.Казань № 1339

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым һәм оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын куллану шартларын салым түләүчеләрнең аерым категорияләрен үтәүне бәяләү тәртибен һәм методикасын раслау турында» 2020 ел, 15 июнь, 495 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым һәм оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын куллану шартларын салым түләүчеләрнең аерым категорияләрен үтәүне бәяләү тәртибен һәм методикасын раслау турында» 2020 ел, 15 июнь, 495 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 апрель, 388 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «19 пункты» сүзләрен «19 һәм 21 пунктлары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым һәм оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын куллану шартларын салым түләүчеләрнең аерым категорияләрен үтәүне бәяләү тәртибенең һәм методикасының беренче абзацында «19 пунктының бишенче абзацында» сүзләреннән соң «, 21 пунктының бишенче абзацында» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин